МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.04.2021 Казан шәһәре № 151

2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алуга әзерлек һәм аны уздыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына субвенция бирү турында килешү формасын раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алуга әзерлек һәм үткәрү буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенция бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 9 апрелендәге 226 номерлы карарын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. 2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алуга әзерлек һәм аны уздыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына субвенция бирү турында килешүнең кушымтада бирелә торган формасын расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары О.В.Пелевинга йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрының
24.02.2021 № 5823.04.2021 №151
боерыгы белән расланды

Формасы

2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алуга әзерлек һәм аны уздыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына субвенция бирү турында килешү формасы

«__» ________ 20__ ел. № ________
(килешү төзү датасы) (килешү номеры)

Бюджет акчаларын бүлеп бирүче булган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, алга таба «Министрлык» дип атала, ________________________________ йөзендә
(Министрлык җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның вазыйфа атамасы)
________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
эш итү нигезе ________________________________,
(Министрлык турында нигезләмә, ышаныч кәгазе, боерык яки вәкаләтләрен раслый торган башка документ)
бер яктан һәм,________________________________,
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты исеме)
субвенцияне алучы булып тора, алга таба – «Муниципаль берәмлек», ________________________________ йөзендә
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның вазыйфа атамасы)
________________________________, эш итү
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
нигезе ________________________________,
(устав, ышаныч кәгазе яки вәкаләтләрен раслый торган башка документ)
икенче яктан, алга таба икесе бергә «Яклар» дип аталып, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына 2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәкпәк алуга әзерлек һәманы уздыру буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен бүлеп бирү турында» 2020 елның 11 декабрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бирү турындагы закон),________________________________

________________________________
____________ «__» ___________ ___-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы
(тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы яки тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы законы)
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 9 апрелендәге 226 номерлы карары белән расланган 2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алуга

әзерлек һәм үткәрү буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенция бирү тәртибе (алга таба – Субвенцияләр бирү тәртибе) нигезендә әлеге Килешүне төзеделәр, түбәндәгеләр хакында.

## I. Килешү предметы

1.1. Әлеге килешүнең предметы булып 20 - _ елда

______________________________________________________________

(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты)

Җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бүлеп бирү турындагы закон нигезендә тапшырылган 2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алуга әзерлек һәм аны уздыру буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенция (алга таба – субвенцияләр, вәкаләтләр, чыгым шартлары) бирү тора.

1.2. Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субвенция торган чыгым юнәлешләренә түбәндәгеләр карый:

халык турында мәгълүмат җыюга җәлеп ителә торган затларны укыту һәм эшләү өчен яраклы, саклана торган, мебель, элемтә чаралары белән җиһазландырылган бүлмәләр белән тәэмин итү;

2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алу кәгазьләрен һәм башка документларны саклау өчен сакланыла торган бүлмәләр белән тәэмин итү;

кирәкле транспорт чаралары бирү;

кирәкле элемтә чараларын бирү.

1.3. Субвенцияләр бирү, әлеге Килешүгә аның аерылгысыз өлеше булып торган кушымта нигезендә, чыгым йөкләмәләрен үтәү чарасын гамәлгә ашыру максатларында гамәлгә ашырыла.

## II. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү

2.1. Субвенция бюджет акчаларын алучы буларак Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә бюджет чыгымнарын классификацияләү кодлары буенча бирелә: Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлеп бирүче коды _____, бүлек_____, бүлекчә _____, максатчан статья ____, чыгымнар төре _____.

2.2. Түбәндәгегә бирелә торган субвенцияләр күләме______________________

______________________________________________________________________:

(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты)

җирле үзидарә органнарына Җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бүлеп бирү турындагы закон кушымтасында каралган 2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алуга әзерлек һәм аны уздыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү

методикасы нигезендә билгеләнгән;

тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы яки тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законга үзгәрешләр кертү турындагы закон закон белән расланган.

2.3.

______________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты)

20___ елда чыгым йөкләмәләрен финанс яктан тәэмин итү өчен каралган субвенцияләрнең гомуми күләме – __________________________________________ (______________________) сум ___ тиен.
(сумманы хәрефләр белән язарга)

III. Субвенцияләрне күчерү тәртибе, шартлары һәм сроклары

3.1. Субвенция Субвенцияләр бирү тәртибе нигезендә бирелә.

3.2. Субвенция түбәндәге шартларны үтәгәндә бирелә:

_________________________________________________________ (кемгә)
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты)

(муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлеге) Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр бирү хисабына чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре булу.

3.3. Татарстан Республикасы бюджетыннан_______________________________

______________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты)

субвенция акчаларын күчерү әлеге Килешү имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек срокта Россия Федерациясе Үзәк Банкы учреждениеләрендә ______________________________________________ бюджет
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты)

акчалары белән операцияләрне исәпкә алу өчен Федераль казначылыкның территориаль органына ачылган шәхси счетка күчерелә.

IV. Якларның бәйләнышлары

4.1. Министрлык түбәндәгеләрне үтәү бурычын үз өстенә ала:

4.1.1. Субвенция бирүне тәэмин итү ___________________________________

______________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты)

әлеге Килешүнең III бүлеге нигезендә.

4.1.2. Муниципаль берәмлек тарафыннан вәкаләтләрнең гамәлгә ашырылуын тикшереп тору, түбәндәгечә:

вәкаләтләрне үтәү турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүматны соратып алу юлы белән;

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 77 статьясында каралган тәртиптә тикшерүләр уздыру юлы белән;

4.1.3. Субвенцияләрдән максатчан файдаланмаган, билгеләнгән срокта хисап тапшырылмаган һәм (яисә), Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләрдә ачыкланганча, Муниципаль берәмлек тарафыннан субвенцияләр бирү шартларын бозу фактлары булган очракта, Муниципаль берәмлеккә

_______________________________________________________________

(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты)

субвенция акчаларын Татарстан Республикасы бюджетына кайтарып бирүне таләп итү.

4.1.4. Субвенция бирү туктатып торылган очракта, мондый туктатылу сәбәпләре турында Муниципаль берәмлеккә хәбәр итү.

4.1.5. Муниципаль берәмлек яки аның вазыйфаи затлары тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру барышында җибәрелгән җитешсезлекләрне бетерү, шул исәптән Җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бүлеп бирү турындагы закон таләпләре бозылу очракларын бетерү буенча язмача күрсәтмәләр җибәрү.

4.1.6. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә субвенцияләрнең максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын контрольдә тоту.

4.2. Министрлыкның хокуклары:

муниципаль берәмлектән әлеге Килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәүне тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм материалларны, шул исәптән бухгалтерлык исәбе мәгълүматларын һәм муниципаль берәмлек тарафыннан субвенция акчаларыннан файдалануга бәйле беренчел документацияне соратырга;

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Муниципаль берәмлек эшчәнлеген координацияләү.

4.3. Муниципаль берәмлек түбәндәге йөкләмәләрне үз өстенә ала:

4.3.1. Әлеге Килешүнең 3.2 пунктында билгеләнгән субвенцияләрне бирү шартларын үтәү.

4.3.2. Субвенцияләр бирү тәртибенең 10 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына акчаларны кире кайтару буенча Министрлык таләпләрен үтәү.

4.3.3. Министрлыкка түбәндәге хисапларны тапшыру:

хисап чоры тәмамланганнан соң өченче эш көненнән соңга калмыйча, квартал саен Субвенцияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымтага яраклы форма буенча 2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алуга әзерлек һәм аны уздыру буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашыру турында;

хисап чоры тәмамланганнан соң өченче эш көненнән соңга калмыйча, квартал саен Субвенцияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымтага яраклы форма буенча 2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алуга әзерлек һәм аны уздыру буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле үзидарә органнарына бирелгән субвенцияләрне тоту турында.

4.3.4. Сорату алынган көннән соң ун эш көне дәвамында Муниципаль берәмлек тарафыннан әлеге Килешүдә каралган йөкләмәләрнең үтәлешен тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм материалларны, шул исәптән бухгалтерлык исәбе һәм Муниципаль берәмлек тарафыннан субвенция акчаларын тотуга бәйле беренчел документларны Министрлыкка тапшыру.

4.3.5. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру барышында Муниципаль берәмлек яисә аларның вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән җитешсезлек фактын (фактларын), шул исәптән билгеле бер срокка Җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бүлеп бирү турындагы закон таләпләре бозылу очракларын бетерү.

4.3.6. Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияне күрсәтелгән таләптә билгеләнгән күләмдә һәм срокларда кире кайтару.

4.3.7. Тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөреслеген һәм субвенцияне максатчан куллануны тәэмин итү.

4.4. Муниципаль берәмлек әлеге Килешүне үтәүгә бәйле аңлатмаларны сорап Министрлыкка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

## V. Якларның җаваплылыгы

5.1. Бу Килешү нигезендә үзләренең бурычларын үтәмәү яисә тиешле дәрәҗәдә үтәмәү очрагында Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

5.2. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне Яклар тарафыннан үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылык турында башка нигезләмәләр:

5.2.1. Субвенцияләр бирү тәртибенең 9 пунктында һәм 10 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән субвенцияне кире кайтару срокларын бозганда, Министрлык әлеге акчаларны законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

## VI. Ахыргы нигезләмәләр

6.1. Яклар арасында әлеге Килешүне үтәү белән бәйле барлыкка килә торган бәхәсләр алар тарафыннан, мөмкин булганча, беркетмәләр яки башка документларны рәсмиләштереп, сөйләшүләр үткәрү юлы белән хәл ителә. Килешүгә ирешелмәгән очракта, Яклар арасындагы бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

6.2. Әлеге Килешү имзалана:

Муниципаль берәмлек тарафыннан, Миинистрлыктан алынган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнелә торган биш көнлек срокта;

Министрлык тарафыннан, Муниципаль берәмлектән имзаланган Килешү алынган көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган өч көнлек срокта.

6.3. Әлеге Килешү Якларның һәркайсы исеменнән эш итәргә хокуклы затлар тарафыннан имзаланган датадан баәлап үз көченә керә һәм субвенция бирелгән елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

Әлеге Килешү предметы буенча яңа килешү төзелгән очракта, Якларның әлеге Килешү буенча йөкләмәләре туктатыла.

5.4. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә әлеге Килешүгә Министрлык тарафыннан үзгәрешләр кертү бер яклы тәртиптә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына кертелгән үзгәрешләр үз көченә кергән көннән башлап бер ай эчендә, Муниципаль берәмлеккә тиешле язма хәбәрн җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Килешүгә кертелгән үзгәрешләр Яклар өчен хәбәрдә күрсәтелгән көннән башлап үз көченә керә.

6.5. Әлеге Килешүгә 6.4 пунктта каралмаган башка үзгәрешләр өстәмә килешү рәсмиләштерү юлы белән, Яклар килешүе буенча кертелә.

6.6. Әлеге Килешү документ рәвешендә ике нөсхәдә, һәр як өчен берәр нөсхәдә төзелде.

## VII. Якларның түләү реквизитлары

| Татарстан Республикасы<br>Икътисад министрлыгы | Муниципаль берәмлек<br>атамасы |
|---|---|
| Урнашу урыны: | Урнашу урыны: |
| Банк реквизитлары: | Банк реквизитлары: |
| Россия Банкы учреждениесенең БИК һәм атамасы<br>Бердәм казна счеты<br>Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счеты<br>Шәхси счет<br>Субвенция алучының исеме<br>ИНН/КПП<br>Төп дәүләт теркәү номеры<br>ОКТМО | Россия Банкы учреждениесенең БИК һәм атамасы<br>Бердәм казна счеты<br>Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счеты<br>Шәхси счет<br>Субвенция алучының исеме<br>ИНН/КПП<br>Төп дәүләт теркәү номеры<br>ОКТМО |

## VIII. Якларның имзалары

| Татарстан Республикасы<br>Икътисад министрлыгы | Муниципаль берәмлекнең<br>кыскартылган исеме |
|---|---|
| __________/________________<br>(имза) (ФИА) | __________/________________<br>(имза) (ФИА) |

2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алуга әзерлек һәм аны уздыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына субвенция бирү турында килешүгә кушымта

Финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып субвенция торган чыгымнар юнәлешләре, 20-_ елга

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең исеме: ______________________________________________
Үлчәү берәмлеге: сум (өтердән соң икенче билгегә кадәр төгәллек белән)

| Чыгымнар юнәлеше | | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү күләме | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Атамасы | БК буенча коды | Барлык чыгымнар | шул исәптән чыгым төрләре буенча | | | |
| | | | халык турында мәгълүмат җыюга җәлеп ителә торган затларны укыту һәм эшләү өчен яраклы, саклана торган, мебель, элемтә чаралары белән җиһазландырылган бүлмәләр белән тәэмин итү | 2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алу кәгазьләрен һәм башка документларны саклау өчен сакланыла торган бүлмәләр белән тәэмин итү | кирәкле транспорт чаралары бирү | кирәкле элемтә чараларын бирү |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алуга әзерлек һәм аны уздыру буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән Субвенция | | | | |

Якларның имзалары:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | ____________<br>(Мун |
| __________/________________<br>(имза) (ФИА) | ________<br>(им |

______________________________